Татарстан Республикасы  Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге составына керүче
Татар Сөнчәлесе авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

2021 ел, 20 ноябрь № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы Татарстан», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019 , № 99 карары нигезендә, 2021 елның 20 ноябрендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәлесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Татар Сөнчәлесе авылында юлларга вак таш сатып алу һәм җәю.

- Татар Сөнчәлесе авылы чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, агынты суларны чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Татар Сөнчәлесе авылында тирән насос сатып алу һәм алыштыру, суүткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ» «Тыелып калды».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 240 граждан кертелгән.

Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны: 123

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 71 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 52 граждан тавыш бирде.

«Тыелып калды» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны танырга: 2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәлесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Татар Сөнчәлесе авылында юлларга вак таш сатып алу һәм җәю.

- Татар Сөнчәлесе авылы чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, агынты суларны чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Татар Сөнчәлесе авылында тирән насос сатып алу һәм алыштыру, сүүткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Мюд авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының http://aksubaevo.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге башлыгы,

гражданнар җыенында рәислек итүче: Т.В. Зюзина